**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬ-НОГО КОМИТЕТА УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТА-НЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423739, деревня Качкиново,
ул. Центральная, дом 37в,
Тел. 3-44-63

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

423739, Качкын авылы, Үзәк ур.,
37в нчы йорт. Тел.3-44-63

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
20.06.2025г.

КАРАР
№10

“Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы “Усы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында” Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты 2020 елның 19 мартындагы 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (28.02.2025 ел, № 6, 24.04.2025 ел, № 8 үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 31 маендагы 828 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 19 мартындагы 8 номерлы (28.02.2025 ел № 6, 23.04.2025 ел №8 үзгәрешләр белән) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Усы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.9 пунктта «шулай ук Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең гомуми бюджет эффектын (үз-үзен аклый торган) стимуллаштыручы салым чыгымнарын бәяләү» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 3.13 һәм 3.14 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"3.13. "Усы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымының нәтиҗәлелеген бәяләү йомгаклары буенча салым чыгымы кураторы муниципаль берәмлек салым чыгымнарының максатчан характеристикасына ирешү, муниципаль берәмлек муниципаль программаларына карамый торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү өчен муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчан характеристикаларына ирешү, муниципаль берәмлек программаларына туры килми торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү һәм (яисә) социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү турында, муниципаль берәмлек программасы максатларына һәм (яисә) социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарының булу яисә булмавы хакында, шулай ук муниципаль берәмлек программаларының һәм (яисә) социаль-икътисадый сәясәтенең максатчан нәтиҗәлелеге һәм (яисә) чыгымнарының төп нәтиҗәлелеге турында нәтиҗәләр формалаштыра.
3.14. Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелегенә бәя бирүне салым

чыгымнары кураторлары биргән мәгълүматлар нигезендә, шул исәптән салым чыгымнары кураторлары биргән ташламаларны саклау (төгәлләштерү, бетерү) турындагы тәкъдимнәрне исәпкә алып, әлеге документның 3.11 пункты нигезендә төзи.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.";

1.3. 3.10_1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.10_1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгеләргә карата үткәрелмәскә рөхсәт ителә:

а) муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнары;

б) муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру вакытына фискаль характеристикалар булмаган муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары;

в) муниципаль берәмлекнең гамәлдә булу срогы бер елдан кимрәк булган ташламаларга бәйле салым чыгымнары.";

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм "Авыл җирлекләре" бүлегендә Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Усы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе З.З.Әхмәев